| СОВЕТ НОРМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ НОРМА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«31» октябрь 2022 ел № 93

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзарасалым җыю һәм файдалану тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законның 56 статьясы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Норма авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Норма авыл җирлеге Советының 2014 елның 11 апрелендәге 112 нче номерлы (2015 елның 06 февралендәге 144 номерлы, 2016 елның 30 сентябрендәге 38 номерлы, 2017 елның 15 ноябрендәге 69 номерлы, 2018 елның 15 ноябрендәге 106 номерлы, 2022 елның 28 октябрендәге 64 номерлы үзгәрешләр белән) карары белән расланган, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзарасалым җыю һәм файдалану тәртибе турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 5.1 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

“Гражданнарның үзара салым акчаларын түләү җирле референдумда кабул ителгән карарларның йомгакларын игълан иткәннән соң өч ай эчендә, 18 яшькә җиткән, җирле референдумда катнашуларына һәм тавыш биргәндә алар тарафыннан белдерелгән мөнәсәбәтләргә бәйсез рәвештә, яшәү урыны Җирлек чикләрендә урнашкан барлык гражданнар тарафыннан башкарыла. Башкарма комитетның банк реквизитларын, шулай ук, түләү тәртибе турындагы мәгълүматны үз эченә алган, җирлекнең Башкарма комитеты хәбәрнамәсе нигезендә, үзарасалым суммасының 90 % күләмендә ташламалар билгеләнгән 1 нче төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышы тол хатыннарыннан, тыл хезмәтчәннәреннән, 80 яше тулып киткән өлкән гражданнардан, 70 яшьтән өлкәнрәк балалары булмаган ялгыз яшәүче гражданнардан, Россия Федерациясе кораллы көчләрендә мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, Россия Федерациясе кораллы көчләрендә контракт буенча хезмәт итүче гражданнардан тыш.”.

2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге Советының 2022 елның 28 октябрендәге 64 номерлы «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Норма авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым җыю һәм файдалану тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында»гы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карар имзаланган көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә (baltasi.tatarstan.ru) «Җирлек» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка житкерергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны авыл җирлеге башлыгы Шарипҗанов Радик Наиловичка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Норма авыл җирлеге башлыгы Р.Н. Шарипҗанов